ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Аерым акционер җәмгыятьләрнең идарә итү органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр турында

«Хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр турында» 2023 елның 20 июнендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыятенең идарә итү органына Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкил итеп сайлап кую өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Зарипов Айрат Ринат улын күрсәтергә.

2. «ТАТМЕДИА» акционер җәмгыятенең идарә итү органына Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр итеп түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры Әминов Илшат Юныс улын;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Зарипов Айрат Ринат улын.

3. «Казан мотор төзелеше җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятенең идарә итү органына Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкил итеп Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе Хамаев Азат Кыям улын билгеләп кую белән килешергә.

4. «Аерым акционер җәмгыятьләрнең идарә органнарына Татарстан Республикасы вәкилләрен күрсәтү турында» 2019 елның 24 декабрендәге 240-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 28 ноябре
№ 120-VII ДС